РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы Лермонтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.04.2019 № 80-п

Саба муниципаль районы Шәмәрдән
авыл җирлеге җирле үзидарә органнары
тарафыннан күрсәтелүче муниципаль
хезмәтләр исемлеген раслау турында

“ Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында, Татарстан республикасы Саба муниөипалҗ районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/shemordan, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Гараев

Шәмәрдән авыл җирлеге
башкарма комитетының
23.04.2019 елгы №80-п
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге

| | |
|---|---|
| 1 | Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару |
| 2 | Белешмәләр (өземтәләр) бирү |
| 3 | Агачлар яки куаклыкларны кисәргә, төпләргә яки утыртырга рөхсәт бирү |
| 4 | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу |
| 5 | Муниципаль торак фондыннан гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү |
| 6 | Муниципаль торак фондындагы торак урыннарын гражданнарга хезмәт торак урынын найм шартнамәләре буенча бирү |
| 7 | Төзелеп беткән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлекләре бирү |
| 8 | Торак төзелеше максатларында аны комплекслы үзләштерү өчен муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеген арендалау шартнамәләрен төзү хокукын сату буенча торглар оештыру һәм үткәрү |
| 9 | Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү |
| 10 | Җирлектәге муниципаль милектәге биналарны, корылмаларны һәм торак булмаган биналарны арендага бирү |